**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**18нче июнь 2020нче** **№ 240**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез нигездә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә яллаучы вәкиле (эш бирүче) рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмә хакында» 2019 елның 19 апрелендәге 196 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» нигезендә, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез нигездә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә яллаучы вәкиле (эш бирүче) рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмә хакында” 2019 елның 19 апрелендәге 196 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**Советы рәисе** **С.К.Маклаков**